Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа-Иглай авыл җирлегенә керүче Некрасовка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«23» ноябрь 2021 ел №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 23 ноябрендә узган: «Яңа Иглай авыл җирлеге Некрасовка торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк гражданнардан кала 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Некрасовка торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

Урамнарны яктыртуны оештыру өчен, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 70 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 47 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 47 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа-Иглай авыл җирлеге Некрасовка торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Яңа Иглай авыл җирлеге Некрасовка торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк гражданнардан кала 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Некрасовка торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

Урамнарны яктыртуны оештыру өчен, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга» .

2. Җыен нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.И. Файзуллин

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы Р.И. Файзуллин